**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ГЛАВА АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.58

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШЛЫГЫ**
422870, РТ Базарлы Матак авылы,
с .Крайнов ур.,58

Телефон: (84346) 20-0-26, 21-0-48, факс: (84346) 21-7-57. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: alkeevskiy.tatarstan.ru.

**П О С Т А Н О В Л Е Н И Е** **К А Р А Р**

2019 нчы елның 16 нчы сентябре 62№

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль
районы территориясендә Гражданнар оборонасы
буенча уку-консультация пунктларын төзү турында

1994 нче елның 21 нче декабрендәге 68-ФЗ номерлы «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» һәм 1998 нче елның 12 нче февралендәге 28-ФЗ номерлы «Гражданнар оборонасы турында" Федераль законнар нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2000 нче елның 2 нче ноябрендәге 841 номерлы «Гражданнар оборонасы өлкәсендә халыкны әзерләү турындагы Нигезләмәне раслау хакында" Карарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 нчы елның 21нче маендагы 1126-р номерлы боерыкларын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы башлыгы КАРАР БИРӘ:

1.Әлки муниципаль районының һәр авыл җирлегендә авыл мәдәният йортлары нигезендә халыкка гражданнар оборонасы өлкәсендә консультация хезмәтләре күрсәтү өчен гражданнар оборонасы буенча укыту-консультация пунктлары (алга таба-ГО буенча УКП) булдырырга. Уку-консультация пунктлары җитәкчеләре итеп авыл мәдәният йортлары директорларын билгеләргә (1 нче кушымта);

2.Авыл җирлекләренә тәкъдим итәргә:

-ГО буенча УКП эшен оештыруны комплектлаштыру буенча чараларны планлаштыру;

-Гражданнар оборонасы өлкәсендә белем алырга тиешле халык исәбен алуны оештырырга;

- ГО буенча УКП оештыру документларын әзерләүдә УКП җитәкчеләренә методик ярдәм күрсәтү.

3.Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы авыл җирлекләренең укыту-консультация пунктлары турында Нигезләмәне расларга (2 нче кушымта).

4.Авыл җирлеге башлыкларына Гражданнар оборонасы буенча укыту-консультация пунктларын булдыру буенча методик һәм практик ярдәм күрсәтергә.

5.Әлки муниципаль районының финанс-бюджет палатасына:

- авыл җирлекләре башлыклары белән берлектә, гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү тематикасы буенча УКПны кирәкле укыту - методик, күрсәтмә һәм тарату материаллары белән тәэмин итәргә

- 2020 нче  елдан башлап авыл җирлекләре бюджетларында Гражданнар оборонасы буенча УКП эшчәнлеген тулы күләмдә гамәлгә ашыру өчен финанс чараларын күздә тотарга кирәк.

6.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенә һәм " ТР буенча 7 ОФПС»федераль дәүләт бюджет учреждениесенең 105 нче янгын сүндерү бүлеге җитәкчесенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Әлки районы Башлыгы: А. Ф. Никошин

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Башлыгының
2019 нчы елның 16 сентябре 62 № Карарына
1 нче Кушымта

Әлки муниципаль районының авыл мәдәният йортлары базасында авыл җирлекләренең Гражданнар оборонасы буенча төзелә торган укыту-консультация пунктлары исемлеге

| № | Исеме | Адресы/ элемтә өчен телефон | Авыл мәдәният йортлары директорларының-УКП начальникларының исем-фамилиясе | Оештырылу турында Документ№, дата |
|---|---|---|---|---|
| | **Әлки муниципаль районы "Әлки район мәдәният бүлеге" МКУ** | | | |
| 1 | Әлки муниципаль районы «Әлки район мәдәният йорты» МБУ | | | |
| 1 | Базарлы Матак район мәдәният йорты | 422870, ТР, Әлки районы, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур., 55йорт | Шәйхетдинов Рөстәм Солтан улы, 88434621015 | 2007 нче ел, 26 нчы гыйнвар ОГРН 107165000021 138№ карары 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.1 | Апак авыл мәдәният йорты | 422888, ТР, Әлки районы, Апак авылы, Тынычлык ур., 1йорт | Хөсәинова Рәмзия Энгел кызы, 89274170044 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.2 | Алпар авыл мәдәният йорты | 422870, ТР, Әлки районы, Иске Алпар авылы, Төньяк ур., 29 йорт | Галиуллина Савия Мөхәммәдулла кызы, 89872118571 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.3 | Әхмәт авыл мәдәният йорты | 422884, ТР, Әлки районы, Әхмәт авылы, Үзәк ур.,.9б йорт | Шәйхутдинова Гөлнара Фәрид кызы, 89375994177 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.4 | Борис авыл мәдәният йорты | 422883, , ТР, Әлки районы, Борис авылы, Дуслык ур., 8 йорт | Дмитриева Анастасия Николаевна, 89274253217 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.5 | Югары Әлморза авыл мәдәният йорты | 422885, ТР, Әлки районы, Югары Әлморза авылы, Пионер ур.,24 йорт | Муратова Лилия Җәмил кызы, 89274227602 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.6 | Югары Колчурино авыл мәдәният йорты | 422873, ТР, Әлки районы, Югары Колчурино, 8-Март ур.,, 21 йорт | Самарина Лариса Николаевна, 89372803089 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.7 | Карга авыл мәдәният йорты | 422870, ТР, Әлки районы, Карга авылы, Үзәк ур., 30 йорт | Хәсәншина Гөлчира Закир кызы, 89274092045 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.8 | Кошки авыл мәдәният йорты | 422892, ТР, Әлки районы, Кошки авылы, Җәлил ур., 21 йорт | Королев Юрий Владимирович, 89297279498 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.9 | Карамал авыл мәдәният йорты | 422877, ТР, Әлки районы, Карамал | Хәсәншин Рамил Нургали улы, | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | авылы,<br>Тукай ур., 20 йорт | 89274166367 | район мәдәният йорты уставы |
| 1.10 | Каракүл авыл мәдәният йорты | 422888, ТР, Әлки районы, Каракүл авылы, Мәктәп ур. 26 йорт | Демьянова Людмила Васильевна, 89274288862 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.11 | Түбән Кәчи авыл мәдәният йорты | 422889, ТР, Әлки районы, Түбән Кәчи, Үзәк ур., 10б йорт | Иванова Марина Аркадьевна, 89179252428 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.12 | Яңа Чаллы авыл мәдәният йорты | 422876, ТР, Әлки районы, Яңа Чаллы, Үзәк ур.,.22 йорт | Фәтхутдинов Тәлгать Исламетдин улы, 89274106488 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.13 | Түбән Әлки авыл мәдәният йорты | 422881, ТР, Әлки районы, Түбән Әлки авылы, Совет ур., 56 йорт | Галяутдинова Рәмзия Әсәдулла кызы, 89372803253 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.14 | Иске Әнҗерә авыл мәдәният йорты | 422882, ТР, Әлки районы, Иске Әнҗерә авылы,Тынычлык ур., 24 йорт | Гатауллин Илшат Габдулхак улы, 89274289869 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.15 | Иске Чаллы авыл мәдәният йорты | 422876, ТР, Әлки районы, Иске Чаллы авылы, Үзәк ур.,.21 йорт | Вафин Әнвар Илгизәр улы, 89274352601 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.16 | Салман авыл мәдәният йорты | 422874, ТР, Әлки районы, Салман авылы, Үзәк ур., 20 йорт | Сәлахов Нургали Солтан улы, 89874192811 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.17 | Иске Матак авыл мәдәният йорты | 422890, ТР, Әлки районы, Иске Матак авылы, Үзәк ур., 7 йорт | Калмыков Сергей Петрович, 89274385281 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.18 | Иске Салман авыл мәдәният йорты | 422894, ТР, Әлки районы, Иске Салман авылы, Клуб ур, 1 йорт | Сункишева Гөлнаҗия Габделнур кызы, 89874139532 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.19 | Иске Камка авыл мәдәният йорты | 422897, ТР, Әлки районы, Иске Камка авылы, Үзәк ур., 38 йорт | Әхметов Радик Хамәтгали улы, 89274251244 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.20 | Ташбилге авыл мәдәният йорты | 422870, ТР, Әлки районы, Ташбилге авылы, Үзәк ур., 5 йорт | Сафина Алсу Рәшит кызы, 89274165713 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.21 | Татар Борнае авыл мәдәният йорты | 422879, ТР, Әлки районы, Татар Борнае авылы, Үзәк ур., 34 йорт | Аглиуллина Рәмзия Минрафик кызы, 89375795517 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.22 | Төгелбәй авыл мәдәният йорты | 422892, ТР, Әлки районы, Татар Төгәлбәе авылы, Шәвәлиев ур., 18 йорт | Сагыйров Хәмит Гөлминсабир улы , 89376107861 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.23 | Үргәагар авыл мәдәният йорты | 422870, ТР, Әлки районы, Ургәагар авылы, Тукай ур., 4 | Фәритова Гөлсинә Габдуләхат кызы, 89274361140 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | йорт | | йорты уставы |
| 1.24 | Кората авыл мәдәният йорты | 422798, ТР, Әлки районы, Кората авылы, Ерганак ур., 10 йорт | Садиванкина Алина Николаевна, 89274207865 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.25 | Чуваш Борнае авыл мәдәният йорты | 422839, ТР, Әлки районы, Чуваш Борнае авылы, Үзәк ур., 102а йорты | Козырева Елена Михайловна, 89376108141 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.26 | Чуваш Кичүе авыл мәдәният йорты | 422882, ТР, Әлки районы, Чуваш Кичүе авылы,Яшьләр ур., 2а йорты | Киямова Гүзәл Шакир кызы, 89274600948 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.27 | Чиябаш авыл мәдәният йорты | 422885, ТР, Әлки районы, Чиябаш авылы, Тынычлык ур., 20 йорт | Галимов Фаил Юныс улы, 89375748795 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.28 | Чуваш Шәпкәсе авыл мәдәният йорты | 422880, ТР, Әлки районы, Чуваш Шәпкәсе авылы, Үзәк ур., 29 йорт | Ермалаев Василий Васильевич, 89274145267 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.29 | Юхмачы авыл мәдәният йорты | 422885, д ТР, Әлки районы,.Юхмачы авылы, Болын ур., 1 йорт | Хасанова Наилә Әгъзам кызы, 89274300311 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.30 | Абдул-Салман авыл клубы | 422890, ТР, Әлки районы, Абдул Салман авылы, Тукай ур.,14 йорт | Мифтахова Разия Габдулла кызы, 89276773199 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.31 | Бибай Чаллысы авыл клубы | 422876, ТР, Әлки районы, Бибай Чаллысы авылы,Туры ур.,6 йорт | Гиниятуллина Рәзина Насыйбулла кызхы, 89375297679 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.32 | Югары Әлки авыл клубы | 422881, ТР, Әлки районы, Югары Әлки авылы, Тынычлык ур., 70 йорт | Мингазова Фәния Тәлгать кызы, 89274148064 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.33 | Югары Кәчи авыл клубы | 422889, ТР, Әлки районы, Югары Кәчи авылы, Үзәк ур., 45 йорт | Миндрюкова Алена Михайловна, 89270312204 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.34 | Югары Матак авыл клубы | 422890, ТР, Әлки районы, Югары Матак авылы, Клуб ур., 1 йорт | Кудряшова Людмила Вячеславовна, 89372837433 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.35 | Демидовка авыл клубы | 422874, ТР, Әлки районы, Демидовка авылы, Яшьләр ур., 4 йорт | Туров Дмитрий Алекскандрович, 89270384365 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.36 | Мулланур-Вахитов авыл клубы | 422885, ТР, Әлки районы, Мулланур Вахитов авылы, Мул.Вахитов ур., 5 йорт | Шәфигуллина Рафидә Сәитгәрәй кызы, 89274125850 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.37 | Түбән Колчурино авыл клубы | 422873, ТР, Әлки районы, Түбән | Амукова Наталья Юрьевна, | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Колчурино авылы, Үзәк ур., 52 йорт | 89274392655 | район мәдәният йорты уставы |
| 1.38 | Түбән Биктимер авыл клубы | 422870, ТР, Әлки районы, Түбән Биктимер авылы, Тынычлык ур., 17 йорт | Мифтахова Руфия Кирам кызы, 89274253655 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.39 | Түбән Салман авыл клубы | 422874, ТР, Әлки районы, Түбән Салман авылы, Үзәк ур., 102 йорт | Фасахова Зөлфия Хәйретдин кызы | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.40 | Иске Томба авыл клубы | 422888, ТР, Әлки районы, Иске Томба авылы, Үзәк ур.,.20 йорт | Соколова Антонида Николаевна, 89375252657 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.41 | Садиково авыл клубы | 422883, ТР, Әлки районы, Садиково авылы, Яшел ур.,5а йорты | Королева Любовь Владимировна, 89270384172 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.42 | Урта Әлки авыл клубы | 422880, ТР, Әлки районы, Урта Әлки авылы, Үзәк ур., 49 йорт | Аглиуллина Рәсинә Әнвәр кызы, 89274126054 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.43 | Татар Мулласы авыл клубы | 422870, ТР, Әлки районы, Татар Мулласы авылы, Клуб ур., 58 йорт | Мөнадиева Рузилә Нургалләм кызы, 89196395249 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.44 | Тахтала авыл клубы | 422894, ТР, Әлки районы, Иске Тахтала авылы, Ежевичная ур., 88а йорт | Барабанова Валентина Петровна, 89274091912 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.45 | Хузангай авыл клубы | 422897, ТР, Әлки районы, Хузангай авылы, Май ур.,1 йорт | Теличко Татьяна Николаевна, 89270373894 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.46 | Хлебодар авыл клубы | 422874, ТР, Әлки районы, Хлебодаровка авылы, Прохоров ур., 4 йорт | Сагыйрова Гөлфия Абдуләхат кызы, 89270395291 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 1.47 | Йолдыз авыл клубы | 422882, ТР, Әлки районы, Йолдыз авылы, Үзәк ур., 10 йорт | Гафурова Майя Владимировна, 89272467284 | 2013 нче ел,18 нче март, 138№ Әлки район мәдәният йорты уставы |
| 2 | Әлки районы муниципаль бюджет киноучреждениесе | 422870, ТР, Әлки районы, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур., 57 йорт | Гайсин Фиргат Газимҗан улы, 88434620087 | 21.12.2006 ел, 274№ Карар, |
| 3 | ТР Әлки МР Мәдәният министрлыгы “С.М. Лисенков исемендәге Туган якны өйрәнү музее " муниципаль бюджет учреждениесе | 422870, ТР, Әлки районы, Базарлы Матак авылы, Крайнов ур., 135 йорт | Платонова Марина Андреевна, 88434621228 | Әлки район халык депутатлары Советының 21.12. 2002 ел, 61 № карары, ТР Әлки МР " С.М. Лисенков исемендәге Туган якны өйрәнү музее"МБУ 10.10.2013 ел 436№ уставы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3.1 | Чуашстанның халык шагыйре П. П. Хузангай музее» | 422897, ТР, Әлки районы, Хузангай авылы, Май ур., 1 йорт | Мурзин Олег Витальевич 88434673433 | ТР Әлки МР " С.М. Лисенков исемендәге Туган якны өйрәнү музее" МБУ 10.10.2013 ел 436№ уставы |

Әлки муниципаль районы Башлыгының
2019 нчы елның 16 сентябрь 62 № карарына
2 нче кушымта

Әлки муниципаль районы авыл җирлекләренең укыту-консультация пунктлары турында **НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Әлки муниципаль районы территориясендә авыл җирлекләрен Гражданнар оборонасы буенча укыту - консультация пунктларын (алга таба - ГО буенча УКП)төзү, җиһазландыру һәм эшләтү буенча төп бурычларны, тәртибен билгели.

1.2. Гражданнар оборонасы буенча УКП Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары, Әлки муниципаль районының Гражданнар оборонасы өлкәсендәге муниципаль хокукый актлары нигезендә төзелә.

1.3. Гражданнар оборонасы буенча УКП тулысынча тыныч вакытта да, сугыш вакытында да, Әлки муниципаль районы территориясе үзенчәлекләрен, алар нигезендә оештырыла торган оешма, предприятие һәм учреждениеләрнең җитештерү эшчәнлеген исәпкә алып, төзелә һәм эшли.

1.4. Гражданнар оборонасының укыту-консультация пунктлары авыл җирлекләре территориясендәге авыл мәдәният йортларында оештырыла.

УКП булдыру вариантлары (финанс мөмкинлекләренә, хезмәт күрсәтелә торган территория зурлыгына һәм анда яшәүче халык санына карап):

Уку сыйныфы-торак пунктта яшәүче халык өчен, 15-20 кеше сыйдырышлы, техник чаралар, күрсәтмә һәм уку әсбаплары, мебель белән җиһазландырылган бүлмә.

Гражданнарны яклау пункты-авыл җирендә яшәүче халык өчен, авыл җирлекләре администрацияләре каршында шәһәр пунктлары аналогиясе һәм охшашлыгы буенча.

Гражданнар яклавы почмагы-авыл җирлегендә, авыл җирлекләре администрацияләре каршында яшәүче халык өчен.

## 2. ГО буенча УКП буенча төп максатлары һәм бурычлары.

2.1.ГО буенча УКП буенча төп максаты- һәр гражданин тыныч һәм сугыш вакытында теләсә нинди гадәттән тыш хәлләрдә дә дөрес эшли алсын өчен максималь дәрәҗәдәге халыкны укуга җәлеп итү.

2.2.ГО буенча УКП буенча түбәндәге бурычлар куела:

-гражданнарны хәзерге заман зарарлану чараларыннан саклау ысулын, хәрби хәрәкәтләр алып барганда яки бу гамәлләр нәтиҗәсендә килеп чыккан куркынычлардан саклау ысулын, хәбәр итү сигналы буенча гамәлләр тәртибен, зыян күрүчеләргә беренче медицина ярдәме күрсәтү алымнарын, күмәк һәм шәхси саклану чараларыннан файдалану кагыйдәләрен өйрәтү;

- аларда теләсә кайсы характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау чараларының һәм алымнарының ышанычлылыгына ышанычлылык булдыру;

гадәттән тыш хәлләр, тыныч һәм хәрби вакыт шартларындагы гамәлләр өчен практика бирергә һәм күнекмәләргә гадәтләндерергә;

-гражданнарның әхлакый-психологик халәтен күтәрергә, тиешле һәм адекват гамәлләр кабул итү өчен килеп туган хәлне дөрес бәяләргә ярдәм итәргә;

-халыкны балаларны яклау кагыйдәләренә өйрәтү һәм гражданнар оборонасы чараларын үтәгәндә аларның куркынычсызлыгын тәэмин итү;

-хәзерге шартларда ГО һәм РСЧС ролен, әһәмиятен һәм бурычларын актив пропагандаларга;

-район звеносы эшчәнлеге белән бәйле халыкка гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча территориаль система эшчәнлеге һәм муниципаль район оешмаларында үткәрелә торган чаралар, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән кисәтү һәм яклау буенча мәгълүмат бирү;

- гадәттән тыш хәлләрдә чаралар күрү һәм гамәлдә булганда халыкны әзерләүне яхшырту һәм мәгълүмати-агарту тәэминатын киңәйтү;

-халыкның барлык категорияләренә тормыш куркынычсызлыгы проблематикасына киңрәк үтеп керүне тәэмин итү;

-янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен үтәү буенча халыкка төп таләпләрне җиткерү.

ГО буенча УКП карата төп таләп - һәркем өчен мөмкинлек, киң колач, кирәкле мәгълүматны аңлаешлы бәян ителештә алу мөмкинлеге. Алар гражданнар оборонасы һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау мәсьәләләренә өйрәтү һәм халыкка мәгълүмат бирү өчен кулланыла.

**3. ГО буенчаУКП оештыру һәм эш тәртибе.**

3.1. Авыл җирлекләре башлыкларына Гражданнар оборонасы буенча УКП оештыру, җиһазлау һәм эш оештыру мәсьәләләре йөкләнә. Авыл җирлеге башлыгы чыгарган норматив хокукый актта билгеләнә:

- ГО буенча УКП нинди оешма һәм базада төзелүе;

- ГО буенча УКП (адресны күрсәтеп), халыкны әзерләү өчен кулланыла торган бүлмәләр буенча урнашкан урыны;

- финанслау һәм матди-техник тәэмин итү тәртибе;

- ГО буенча УКП эше өчен җаваплы затлар исемлеге.

3.2. ГО буенча УКП Методик җитәкчелеге хезмәткәрләре, махсус авыл җирлекләре администрацияләрендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бурычларны хәл итәргә вәкаләтле затлар. ГО буенча УКП оештыру структурасы, финанс мөмкинлекләренә, хезмәт күрсәтелә торган территория зурлыгына һәм анда яшәүче халык санына карап, төрле булырга мөмкин.

3.3.УКП буенча ГО һәм ГТХ тематикасы буенча күрсәтмә әсбаплар, әдәбият һәм методик материал, шәхси саклану чаралары үрнәкләре белән җиһазландырылган халык һәм предприятиеләр персоналы белән дәресләр үткәрү өчен билгеләнгән махсус бирелгән бина (урын).

3.4.ГО буенча УКП эше халыкка (эшчеләргә һәм хезмәткәрләргә) күрсәтмә әсбаплар, газета һәм журнал материаллары эчтәлеген мөстәкыйль өйрәнү, яки аеруча авыр темалар һәм кызыксындырган мәсьәләләр буенча консультацияләр үткәрү юлы белән оештырыла.

3.5.Базаларында уку - консультация пунктлары булдырыла торган авыл җирлекләре башлыклары, оешма җитәкчеләре ГО буенча УКП оештыру, карап тоту һәм оештыру өчен җаваплы.

3.6.ГО буенча УКП составына, кагыйдә буларак, консультантлар (инструкторлар) керә.Консультант-инструкторлар итеп гражданнар оборонасы, халыкны тыныч һәм хәрби вакыт гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә иң әзерлекле, «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча уку - методик үзәге» ДБУ һәм аның филиалларында белем алган затлар билгеләнә.

3.7.Авыл җирлекләрендә ГО буенча УКП начальнигы итеп, гадәттә, авыл җирлеге башлыгы билгеләнә. Укуларның турыдан-туры оештыручылары булып базасында УКП төзелгән оешмалар һәм учреждениеләр җитәкчеләре тора.Алар чыгарган боерыкта (күрсәтмәдә) түбәндәгеләр билгеләнә:

- ГО буенча УКП эш тәртибе (тәртип, гадәттә, бинага үзәк керү юлына эленә);
- ГО буенча УКП лекцияләр, әңгәмәләр, консультацияләр, күнегүләр үткәрү өчен җәлеп ителә торган консультантлар (инструкторлар);
- консультантларның (инструкторларның) вазыйфаи бурычлары;
- УКП өчен йортларда (урамнарда) яшәүчеләрне беркетү;
- уку төркемнәренең саны һәм составы;
- лекцияләр, консультацияләр, күнегүләр үткәрү вакыты;
- әдәбият, уку әсбаплары һәм техник укыту чаралары белән тәэмин итү тәртибе.

ГО буенча УКП эшен оештыруда таянырга кирәк:

-Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Президенты указларына, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Хөкүмәте карарларына, Әлки муниципаль районының норматив хокукый актлары һәм әлеге Нигезләмәгә;

-авыл җирлеге башлыгы указлары һәм боерыкларына;

- ГО буенча УКП эшен регламентлаучы башка җитәкче документларга.

**4. ГО буенча УКП эшләнелә торган документлар исемлеге.**

4.1.Планлаштыручы документлар:

-ГО буенча УКП төзелгән оешма җитәкчесенең эшен оештыру, консультантлар (инструкторлар) билгеләү турында боерыгы;
- ГО буенча УКП нигезләмә;
- 20____ елга халыкны ГО буенча УКПта әзерләү планы;
- ГО буенча УКП эш тәртибе;
- ГО буенча УКП хезмәткәрләре дежурлык графигы;
- халыкны әзерләү программасы (темаларның эчтәлеге белән).

4.2.Әзерлекне исәпкә алу буенча документлар:

- уку елына дәресләр һәм консультацияләр расписаниесе (һәр инструктор-консультант өчен);
-укучыларның дәресләрен һәм йөрешен исәпкә алу журналы;

- тормыш иминлеге өлкәсендә консультация сорап мөрәҗәгать иткән халыкны исәпкә алу журналы;

- янгын куркынычсызлыгы буенча инструктажларны исәпкә алу журналы.

4.3. Укыту-методик материаллар:

- расланган программалар нигезендә дәресләр үткәрү буенча методик эшләнмәләр;

- халык белән үткәрелә торган тренировкаларның тәкъдим ителгән тематикасы;

- халык арасында тарату өчен белешмәлекләр, листовкалар, буклетлар һ.б. материаллар. Шулай ук:

- Әлки муниципаль районы вазыйфаи затларының исемлеге һәм телефон номерлары;

- халык исемлеге.

ГО буенча УКП оештыру, җиһазлар, укыту - матди тәэмин ителеш чыгымнары гамәлгә ашырыла:

- авыл җирлекләре бюджетлары хисабына (авыл җирлекләре администрацияләре каршындагы ГО буенча УКП карата);

- ГО буенча УКП базасында булдырылган оешмалар хисабына.